# Үлем хакыйкатен аңлау

Бәлки дәбу макаләтормышыгыз турында яңадан уйлану өчен үлемегездән алда сезгәбирелгән соңгы форсат, соңгы хәтерләтү, соңгы уяру. Сез бу юлларны укыган вакыт берәр сәгаттән соңисән булуыгыздан имин түгел. Берәр сәгаттән соңтормышта булсагыз, киләсе сәгатькәирешүегезнеңһич тәгарантиясе юк. Сәгатьтүгел, бер минут, хәтта бер секундтан соңда исән булуыгыз катгый түгел. Бу мәкаләне соңына хәтле укып бетерүегезнеңдәһичбер гарантиясе юк. Улем сезгә, бөек ихтимал, бер минут алда улем акылыгыздан һич үтмәгән бер мизгелдәирешәчәк.

Искәрмәсез үләчәксез. Бөтен сөйгәннәрегез дәүләчәкләр. Сездән алда яки соңрак әлбәт үләчәкләр.

Үлем дип атаганыбыз асылында нәрсәһәм ничек тормышка аша?

**Үлем вакыты**

Хәзергегәчә, башта үлеп соңыннан да терелеп кайтып, кешеләргәниләр күргәнен, ниләр хис иткәнен аңлаткан һичкемсәдәюк. Шул сәбәпле, үлемнеңнәрсәбулганлыгын, бер кешенеңүлем вакытында ниләр хис иткәнен белүебез өчен техник мөмкинлекләребез юк.

Ләкин, кешегәтормыш бирүче һәм вакыты килгәч аны алучы Аллаһ, үлемнеңничек булганлыгын Көрьәндәбезгәбелдергән. Шул сәбәптән, үлемнеңничек тормышка ашканлыгын, үлүче кешенеңниләр яшәгәнен, ниләр хис иткәнлеген  Көрьәннән өйрәнәалабыз.

Башта Аллаһбезгәкайбер аятләрендәүлем вакытында үлүче кеше тарафыннан күрелгән, ләкин башка кешеләр күрмәгән вакыйгалар турында белдерә. АллаһВакиа сүрәсендәшулай боера: **«җан бугазга килеп терәлгәнедә ки, ул вакытны сез (барытик) карап торырсыз, Без аңа сездән тагын да якын, ләкин күрмәссез.»** (Вакиа сүрәсе, 83-85)

Аллаһбер башка аяттәдәбу «күрелмәгән вакыйгаларның» инкярчылар өчен бик газаплы вакыт булганлыгын шулай тәфсилли:

**«Аларның маллары һәм балалары сине кызыктырмасын. Аллаһ шулар белән барытик аларны дөньяда газапландырыга һәм җаннарының, алар инкярчылардан булган килеш, авырлык белән чыгарылуын тели.»**(Тәүбәсүрәсе, 85)

Мөэминнәрнеңүлеме исә«йомшаклык, яхшылык» белән була: «**Ки, фәрештәләр җаннарын йомшаклык белән алган вакытта: «Сәлам сезгә!»- диярләр. «Эшләгәннәрегезгә каршылык буларак җәннәткә керегез.»** (Нәхл сүрәсе, 32)

Бу аятьләрдәАллаһбезгәүлем хакында бик әһәмиятле һәм үзгәрмәс чынлыкны хәбәр бирә: үлем вакытында үлгән кешенеңкичерешләре белән тышта аны күзәткән кешеләрнеңкүргәннәре бик аермалы. Үрнәге, гомере буе туры юлга керергәтеләмәгән һәм азгын берәр инкярчының үлеме тыштан күзәткәндәтыныч йоклап китүкебек кенә, "рәхәт" үлем белән үлүкебек кенәкүренергәмөмкин. Югыйсә, шул вакытны башка үлчәмгәкүчүче рухы олы газаплар, әрнүләр эчендәүлемне тата бирә. Яки киресенчә, иза чиккән дип саналган берәр мөэминнеңрухы, Аллаһаяттәбелдергәнчә, фәрештәләр тарафыннан "йомшаклык, яхшылык" белән алына.

Шулай итеп, үлем инкярчылар  өчен бөек авырлык, зарар, мөминнәр өчен бөек нигьмәт һәм җиңеллек.

**Гәүдә**

Үлем белән бергәрух, бу дөньдагы кешеләр яшәгән үлчәмнән аерылып, биредәҗансыз тәнен калдырыр һәм хакыйкый тормышка таба юнәлер.

Ләкин, биредәкалган гәүдәнеңязмышы да мәгънәле һәм әһәммиятле. Бигрәк тәбу гәүдәгәисән чакларында кирәгеннән артык әһәммият биргәннәр өчен…

**Үлгәннән соң бу гәүдәнең белән ниләр булачагын җентекле буларак һич уйлаганыгыз булдымы?**

Бер көнне үләчәксез. Бәлки дәһич көтелмәгән рәвештә. Кибеткәбарган вакытыгызда казага дучар була аласыз. Яки дәтуктата алмаслык берәр чир тормышыгызны тәмамлаячак. Яки бер мизгелдәйөрәгегез тибүдән туктаячак. Ләкин, һичшиксез үләчәксез…

Бу мизгелдән алып гәүдәгез белән һичнинди бәйләнешегез дәкалмаячак. Гомере буена «мин» дигәнегез һәм хуҗа булынган тәнегез бер ит кисәге хәлендәкалачак. Үлемегез белән бергәгәүдәгезне башка кешеләр ташый башлый. Тирәюньдәелаучылар, «әле кичәгенәарабызда иде», «тау кебек кеше иде», «бик җитез хатын иде»- дип дииючеләр пәйда булачак. Гәүдәгезне алып өйнеңберәр бүлмәсенә, бәлки дәморгка илтәчәкләр. Иртәгесе көнне күмүэшләре башланачак. Җансыз гәүдәгезне гөселханәгәкитерәчәкләр. Андагы кеше кап-катыга әверелгән гәүдәгезне суык су белән юачак. Бу вакытта тәнегездәүлем эзләре ачык рәвештәүзен күрсәтәчәк. Тәнегез зәңгәр төскәкерәбашлаячак. (HarunYahya, Ölüm, Kıyamet, Cehennem)

**Күмү вакыты**

Бераздан тәнегезне ак тукымадан торган кәфенгәтөрәчәкләр. Тактадан табутка урнаштырып, өстен яшел тукыма белән каплаячаклар. Соңыннан җеназа машинасы да киләчәк, табутны алачак. Кайбер кешеләр җеназа үтәдип үзләренеңхөрмәтләрен күрсәтәчәк, күпчелеге берни дәбулмангандай үз эшләрендәбулачак. Зиратка киленәчәк. Табут сезне яраткан кешеләр кулыннан да, яраткан кебек күренгән кешеләр кулыннан дәүтәчәк. Якында тагын елаучылар, кайгыручылар булачак. Соңыннан үзеннән качу мөмкинлеге булмаган, кабер дип аталган җиргәкитерелерсез. Сезнеңисемегез инде язылган...Гәүдәгезне табуттан чыгарып кабернеңэченәсалачаклар. Кәфенегезне чишәчәкләр. Кулларына көрәк алганнар өстегезгәтуфрак ата башлаячак. Туфрак әкрен-әкрен кәфенегезне каплаячак. Бераздан озатучыларыгызныңэшләре бетәчәк һәм алар таралачаклар. Зират һәрвакыттагыча тирән тынычлыгына биреләчәк. Китүчеләр кире үзләренеңкөндәлек тормышларына кайтачаклар. Ләкин, күмелгән тән өчен тормышныңбернинди мәгънәсе дәинде калмаган. Гәүдәөчен бар булган нәрсә- кара туфрак.

Хакыйкый иман итмәгән кешеләр тарафыннан шул җансыз гәүдәнеңбу гыйбрәт бирүче, кире кагыла алмаслык, кача алынмаслык язмышы бик кайгылы һәм караңгы буларак күрелә. Чөнки алар үлем турында уйланырга теләмәсләр һәм үлем белән бәйле булган һәрнинди уйдан да кача алганнары кадәр качарга тырышырлар. Алар үзләрен бары гәүдәдән гыйбарәт санарлар, дөньяга бик нык бирелерләр. Ләкин үлем турында, Ахирәт турында уйланмау үзалдау механизмнары аларны җаваплылыктан һич тәкоткармаячак.

Иман иткәннәр белерләр ки, үлем белән рух гәүдәне калдырып, алар Аллаһка, тасвирлана алынмаган гүзәл тормыш үлчәменәкавышыр…

https://www.harunyahya.info/tt/maekalaelaer/UElem-hakiykaten-anglau